ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.09.2023 г.Лениногорск № 2669

«Лениногорск муниципаль районы муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренең хезмәт хакы түләү шартлары турында» 2018 елның 31 августындагы 1276 номерлы Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 26 июлендәге 645 номерлы һәм 2022 елның 15 июненедәге 566 номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» карары нигезендә, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренең хезмәт хакы түләү шартлары турында» 2018 елның 31 августындагы 1276 номерлы Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге гомуми белем бирү учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәдә:

1-3 номерлы кушымталарның I бүлеге 2 пунктындагы 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Оклад (вазыйфаи оклад) - компенсация, кызыксындыру һәм социаль түләүләрне исәпкә алмыйча календарь ай өчен хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәгән өчен хезмәткәрнең хезмәтенә түләүнең беркетелгән күләме;»;

1-3 номерлы кушымталарның I бүлеге 2 пунктындагы 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«База хезмәт хакы (база вазифа оклады), хезмәт хакының база ставкасы - минималь хезмәт хакы (вазыйфа оклады), компенсацион, стимуллаштыручы һәм социаль түләүләрне исәпкә алмыйча, тиешле һөнәри квалификация төркеменә керүче эшче яки хезмәткәр вазыйфасы буенча һөнәри эшчәнлек алып баручы дәүләт яки муниципаль учреждение хезмәткәренең хезмәт хакы ставкасы.».

2.Әлеге карарны рәсми публикатор - «Лениногорские вести» газетасында урнаштырырга, Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга, гражданнар танышу өчен мөмкин булган мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче З.Г. Михайлова

И.Р.Хәйбрахманов
5-44-72